БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
4 июнь 2024 ел

**КАРАР**
№ 254

**Балтач муиниципаль районының депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үзенең, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнарга туры китереп, Балтач районы прокуратурасының 2024 елның 14 мартындагы 02-08-01-2024/ Прдп88-24-20920011 номерлы протесты, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Советы **карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2020 елның 29 маендагы 249 номерлы карары (188 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге редакциядә) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү сизелерлек булмаса", керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында карар кабул итү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:

«2.2.Муниципаль вазыйфаны биләүче зат «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен шул очракта җаваплылыктан

азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә күрсәтелгән затларга бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль районы башлыгы
Балтач район Советы рәисе — Р. Р. Нотфуллин